**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахит авыл җирлегенең Загорье торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**1 ноябрь 2024 ел.** **№1**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2024 елның 1 ноябрендәге гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча түбәндәге сорау буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде: "Сез 2025 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән:

1) Загорье торак пунктында урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү;

2) Загорье торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә яраклы рәвештә: сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 57 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә 38 кеше катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" - 38 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" - 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Азнакай муниципаль районының авылы җирлегенең Вахит авыл җирлегенең Загорье торак гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

"Сез 2025 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән:

1) Загорье торак пунктында урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү;

2) Загорье торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

3. Әлеге карарны Вахит авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.,

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахит авыл җирлеге Башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Азнакай муниципаль районының
халык җыенында рәислек итүче,
Вахит авыл җирлегенең Башлыгы Г.И. Әскәрова